Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Көек авылындагы Северная урамының
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

21 декабрь, 2025 ел № 12

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге җирлеге Көек авылындагы Северная урамында яшәүчеләрнең 2025 елның 21 декабрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны - 134 (йөз утыз дүрт).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны - 81 (сиксән бер).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан - 81 (сиксән бер).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә гражданнар җыенының түбәндәге сорау буенча карары: «Сез, 2026 елда Богородский авыл җирлеге Көек авылындагы Северная урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 11 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә Северная ур.) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Богородский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы Д.Ю. Булыгин